ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 439-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Л.Р. Кадермәтова, Ш.Г. Яһудин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 439-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2066-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев, Л.Р. Кадерматова,
Ш.Г. Яһудин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 пунктчасында «республика максатчан программаларын» сүзләрен «дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

2) 12 статьяның 6 пунктында «табигый комплексларына» сүзләрен «табигый экологик системаларына, табигый комплексларына һәм үсемлекләр, хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге булган объектларына» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керүче (аерым нигезләмәләрдән тыш) «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 18 мартындагы 77-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Җир кодексының махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләренә багышланган 95 статьясына дәүләт табигать тыюлыклары, милли парклар, табигать парклары һәм табигать ядкарьләре янындагы җир кишәрлекләрендә һәм су объектларында төзелүче саклау зоналарында гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек нәтиҗәсендә аларга карата тискәре йогынты ясалмаска тиешле объектларны күрсәтү өлешендә үзгәрешләр кертелде.

Закон проекты белән федераль законнардагы бу үзгәрешләрне Татарстан Республикасы Җир кодексының махсус сакланылучы территорияләр җирләренә багышланган 12 статьясында чагылдыру тәкъдим ителә.

Шулай ук закон проекты белән Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына төгәлләштерү үзгәрешләре кертелә.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарны таләп итми.